**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«30»июль 2019 ел** **№126**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 нче декабрендәге 123 номерлы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлегендә җирдән файдалану, муниципаль берәмлек төзелешләре кагыйдәләрен раслау турында” карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 27 февраль, 133 нче номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында»гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының карары 18 декабрь 2014 ел № 123 белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берлегенең җирдән куллану һәм төзелешләр кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

36 статьяның 2 пунктындагы унынчы абзацында « торбаүткәргечләрнең сак зоналарындагы җирләрдән файдалану тәртибе ( Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 20 августындагы 395 номерлы карар»ы белән расланган) төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Яңасала авылы, Үзәк ур., 1;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Шәпкә авылы, Клуб ур., 14,шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге” башлыгы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге” Советы рәисе**

**И.Х.Шиһабеев**